**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

24.04.2015 ел № 59/1

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Советы депутатлар сайлауларын үткәрү өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Советының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 26 статьясы нигезендә

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Советы депутатлар сайлауларын үткәрү өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын расларга.
2. Әлеге карарны «Светлый путь» («Якты юл») район газетасында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Советы Рәисе М.Г. Фазылҗановка йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе М.Г. Фазылҗанов